# ИЗГЕ ҖАНЛЫ ТАБИБӘ

**Тормышны, кешеләрне яратучы, эшенә тогры, үзе өстендә күп эшләүче, тынгысыз табибә Лилия Рафик кызы белән гәзит укучыны күптән таныштырасым килә иде. Бик тә кешелекле, кечелекле, эшенә таләбчан, сабыр, акыллы җан ул.**

Лилия кечкенәдән үк табибә булырга хыяллана. Аның, әнисе кебек ап-ак халат киеп, муенына фонедоскоп асып, уколлар салып, авыруларны карап, уларны дәваларга хыяллануп, курчаклары белән дә гел табибә булып уйнаганы исендә.

Балачак хыяллары тормышка аша уның. Урта мәктәпне яхшы билгеләргә генә тәмамлагач, медицина институтына укырга инә.

Әнисе Рәзилә шатлык яшьләрен йотып, елмаеп, колачларын җәйеп каршы ала кызын. Шул көнне Лилияләрнең өендә олы бәйрәм була - әнисе Коръән ашы әзерләп табын кора. Шатлыгы эченә сыймый: Лилиясе табибә булачак. Үзе гомере буе табиб булырга хыялланган иде дә бит, аңа бары шәфкать туташы булып эшләргә язган. Ана барында риза, шөкер кыла.

Лилия мединститутның педиатрия бүлегендә бик тырышып укый, үзе сайлаган һөнәренең серләренә төшенә. Акыллы кыз югары уку йортын тик яхшы билгеләргә генә тәмамлый һәм балалар табибы булып эшли башлый.

- Республикабызның тән авырулары дәваханәсендә хезмәт юлымны башладым. Тәүдә бер ел интернатура үттем. Бу елны бик күп нәрсәгә өйрәндем. Үземнең тәҗрибәле остазларыма: баш табибыбыз Барис Гата улы Латыповка, баш табибның дәвалау буенча урынбасары Зилә Зия кызы Сулеймановага, бик рәхмәтлемен.

Безнең дәваханә хезмәткәрләре тату гаилә кебек, бергәләшеп, киңәшләшеп эшлибез. 1983 елдан бирле Затонда урнашкан дәваханәнең матди-техник базасы да даими ныгытыла, территориясе төзекләндерелә, тышкы кыяфәте матурлана. Бында төрле районнардан, авыллардан килгән бер меңнән артык авыру дәвалана.

Поликлиникасы, анализлар ясау өчен зур лабораториясе, физик кабинеты, энә белән дәвалау кабинеттары эшли. Балалар бүлекчәсендә ике айлык сабыйлардан 18 яшькә тиклемге 40 бала псиориаз, экзема, нейродермит кебек тән чирләреннән дәвалана.

Бында эшләвемә дә 20 ел тулды. Балаларны яратам, алар фәрештә бит, тогрылар, алдаша белмиләр, күҙеңә генә карап торалар.

Үз телемне белгәнемә биктә куанам. Беренчедән әнкәйемә рәхмәтлемен. Балачактан ул безнең белән татарча сөйләште, туган телебезгә өйрәтте. Үз телеңне белү бигерәк тә кирәк. Бигерәк тә районнардан, авыллардан килгән балалар, олылар белән сөйләшү, киңәш бирү, дәвалау өчен дә туган телдә сөйләшү мөһим.

Әнием - иң якын киңәшчем. Туган телгә, дин әдәпләренә дә ул өйрәтте. Мин дә өйдән чыкканда, эшкә барганда "Бисмилла"ны әйтеп, ул өйрәткән догаларны укымыйча, эш башлаганым юк. Мин бит мөселман кызы.

Дәваханәбездә намаз укыган апалар да ята. Мин бүлек мөдире булгач, аларга ничектә яхшы шартлар булдырырга, намазын укырга урын табарга тырышам. Аллага шөкер! - ди табибә.

Намыслы хезмәте, медицина өлкәсенә китергән тырышлыгы өчен миһырбанлы, тәҗрибәле табибә Лилия Латыпова "БР-ҙың һаулык һаклау отличнигы" тигән мактаулы исемгә лаек булган. Бынан тыш, пациенттарыннан килгән рәхмәт хаттары ла байтак. Һәрберсеннән табибәгә хөрмәт һәм ихтирам тулы сүзләр бөркелә. Барсыда әнисенең яхшы тәрбиясеннән килә.

Әнкәсе Рәзилә Хәжиәхмәт кызы Чишмә районының Бишкәзә авылында тугыз балалы гаиләдә туып үскән. Җиде яшеннән үк намазга баса. Укымышлы әти-әнисе кызларын мәдрәсәдә укытып белем бирсәләр дә, авыр еллар кагылып, барын да камчылап, юк итергә өлгерсә дә, яшли ятлап алган догаларны, Коръән сүрәләрен исендә тота. Авыр заманаларга карамастан, Рәзиләнең әнисе бер намазды да калдырмый укый, тәсбихен тарта, дин юлыннан тайпылмый, балаларын да яхшы, намыслы итеп тәрбияли. Рәзилә үзе дә улы Роберт һәм кызы Лилияне шушы өлгелә үстерә.

- 2007 елда балаларым мине хажга җибәрде, шушындый зур бәхет бүләк



итте. Лилиямнең кызы Карина хәзер минән догалар өйрәнә. Шөкер, оныкларым "нәнәйем" дип өзелеп тора.

Елына ике тапкыр Коръән ашлары узгарам. Балаларым да иманлы булып үсте. Аллага шөкер, кызым табибә булгач, аңа дуслар да, туганнар да, күршеләр дә ярдәм, киңәш сорап еш киләләр.

Һәрберсенә ярдәм кулы сузарга әзер тора, савап булсын үзенә. Барлык борчулардан, сырхаулардан, күңел төшенкелегеннән бер дәва бар - хезмәт! - ди бәхетле ана.

# МӨНИРӘ МӘЧЕТЕНДӘ ИФТАР



Изге Рамазан аеның бер җомгасында Мөнирә мәчетендә ифтар узгарылды. Нижегородка бистәсендәге яңа мәхәббәт мәчет, әйтерсең дә, буй сынына сокланып, янындагы үрдәкле күлгә бакканда тынып калган. Кич шундый тыныч, хәттә тирә-яктан агачларның, үләннәрнең бер генә яфрагы да кузгалырга, селкенергә базнат итмиләр. Күк йөзе аяз, кем белә, бәлки, кадер кичәседер. Тынлык, илаһи матурлык!

Матурлыкка соклана-соклана асыл киемнәр киеп, берберсенә сәламнәр биреп, Мөнирә мәчетенә ифтарга халык җыелды. Улар арасында абруйлы кунаклар - "Ихлас" мәчетенең имам-хатибы Мөхәммәт Галләм, Морат Лукманов, мәчетнең имамы, шәкертләр, талантлы, билгеле хатын-кызлар: могаллимә Фатыйма Фаткуллина абыстай, Башкортостан хатын-кызлары советы рәисе Рәшидә Солтанова, Башкорт хатын-кызлары җәмгыяте рәисе Гүзәл Ситдикова, "Сәхипҗамал" татар хатын-кызлары җәмгыяте рәисе Гөлҗиһан ханым һәм башкалар бар иде.

Алар белән Фатыйма ханымның укучылары - милли киемнәрдәге йәш кызлар да килгән иде. Ифтарга чакырылган барча кунакларны нурлы йөзле хуҗабикә Мөнирә Ләбиб кызы белән уның 85 яшьлек әнисе Әклимә абыстай каршы алды.

Мәчет алдында тәмле былау исләре тирә-якка таралса, мәчетнең аш бүлмәсеннән татлы аш исләре мул табынга чакыра. Өстәл түреннән ир-атларыбыз урын алса, икенче яктан асыл хатын-кызларыбыз утырышты. Табынны моңлы көчле тавышы белән "Ихлас" мәчетенең имам-хатибе Мөхәммәт Галләм ачып җибәрде. Коръән сүрәләре, догалар укылгач, татлы җәннәт ризыклары белән авыз ачкач, барыбыз да мәчетнең зур залында намаз укыдык. Намазда яшьләрнең күп булуы куандырды.

Мөнирә абыстайга Аллаһның рәхмәте булсын. 70тән ашау кешене очраштырып, мул табын корып, авыз ачтырып, олы савапны булды.

Көтеп алган Рамазан аебызда бергә-бергә ифтарларда очрашып, авыз ачу, намазлар уку - үзе зур бәхет. Әгәрдәки 50-80 ел вафат булган әбкәйләребезгә әлеге заманның бер мәчетен генә күрсәтсәң, шундый куанырлар иде. Ислам диненең ачык ишекләренә, китапларына, мул ризыклы табыннарына шөкер кылып, намазларыбызда аларның рухларына догалар кылырга язсын. Амин!

Аллага шөкер, барыбызда тәрәвих намазларыбызны укып, хужабикә Мөнирә абыстайыбызга рәхмәтләребезне әйтеп, өйләребезгә таралыштык. Әлхәмделиллаh! Тагыда килергә язсын бу күркәм Мөнирә мәчетенә!

Кеше үз гомерендә агас утыртырга, кое казып калдырырга, көсә житсә, өй төзергә, хаж кылырга, мәчет салдырырга тиеш дигәннәр. Безнең арада да шундый батыр, кыю, асыл ханымнар бар. Шуларның берсе - Мөнирә Ләбиб кызы күркәм мәчет салдырган да инде. Тырыш ханым язмышына төшкән авырлыкларны җиңеп, биргән вәгдәсен үтәп, изге юлында йөргәнендә аңа Аллаһы Тәгалә ебәргән сабырлык һәм көчкә таянган.

Мөнирә Ләбиб кызының картәтәсенең әтиседә район хуҗаларыннан рөхсәт алып Кушнаренко районында тау башына мәчет сала һәм изге йорт янына яшьләр яңа өйләр салып яши башлыйлар. Еллар үтү белән Яңа Рәсмәкәй дигән авыл барлыкка килә. Хәзер ул Чакмагыш районына карый. Мөнирә ханымның әнкәсе Әклимә Хәсән кызына 85 яшь. Әткәсе Ләбиб Сәетбаттал улы Бөйөк Ватан һугышында катнашып, ике орден кавалеры булган. Мөнирә ханымның әти-әнисе бик тату яшиләр, 8 балага гомер бүләк итәләр. Мөнирә җиденче бала булып дөньяга килә.

Әклимә абыстай, өлкән яшенә карамастан, хәтере яхшы, намазын укып, тәсбихен тартып, кызына киңәшләрен биреп утыра.

- Шушындый күркәм көннәргә килеп җиткәнемә шөкер кылам, бер Аллаһы Тәгаләгә генә ышанам. Мөнирә кызыма мәчет салырга Ул ярдәм итте, теләкләрем кабул булды. Картатием Сәйфелмөлектә мәчет салдырган, ләкин кызганычка каршы, алар заманына авыр кара еллар туры килгән. Яңа төзелгән, намазлар укылган мәчетнең манарасын кисеп, клуб, ары мал азбары ясаганнар. Исемдә, шул мәчет манарасын кисеп төшергән адәм балаларының берсендә сугыштан әйләнеп кайтмады. Нишлисең инде, тәкдирләре шул булгандыр.

Минем картатием Сәйфелмөлек эшкуарлык белән шөгелләнгән: авыл халкыннан бодай, талкан, йомырка алып китеп, Бәйгелде базарында алыштыпып, кирәк-яраклар алып кайтып биргән. Ул колхозга кермәсәдә, халкына тогры хезмәт иткән, авыл халкы арасында хөрмәткә лаек кеше булган. Кызганычка каршы, 1939 елда сукыр эчәктән генә вафат була. Ул жор фикерле, ярдәмчел, укымышлы белем иясе була. Урыны җәннәттә булсын! - ди Әклимә абыстай.

Мөнирә урта мәктәпне тәмамлагач, өч ел читтән торып саудә техникумында белем ала. Уку йортын тик яхшы билгеләргә генә тәмамлагач, Стәрлетамак шәһәренә эшкә юллана. Кала базасында тауарлар буенча белгеч булып эшли башлый. Яшьлек үзенекен итә: соклангыч кызга Рәис исемле җигет гашик була. Яшьләр озак уйлап тормыйча, никах укытып, туй ясый. Яңы йәш гаилә туа.

Яшьләр туй акчаларын җыеп, Өфөгә кайтып, Нижегородка бистәсендә өй сала. Яңа йортка ямь биреп, ир бала дөньяга килә. Гомерләр уза тора, гаиләгә тагы бер кыз туа.

- Хәзер улымның өч баласы - Ислам, Сәмирә, Әсман, ә кызымның Әминә исемле кызы үсә. Улым әтисе кебек җигәрле, Аллага шөкер, төзелеш эше белән шөгелләнә. Киленемнән дә уңдым. Уларны бик яратам, - ди куанысын яшермәй Мөнирә ханым. - Гаҗәп, безнең гаиләбезнең нәсел җепләрен җентекләп, барлап чыксаң, эшкуарлык стажы 350 елдан ашып китә. Барыбыз да көнне төнгә ялгап эшләдек, кәсебебездән килгән байлыктан фәкирләргә, ятимнәргә өлеш чыгардык. Изгелек беркайчан да югалып калмый бит. Ходай безгә икеләтә кайтара.

Мөнирә ханым Нижегородка бистәсендә базар тота. Уны асыу тарихын да бәян итте.

- Ул базар урыны бер чүп җыелган урын булсада, күп юлларга туры килде. Мин ул дәвердә районыбызның Совет депутаты идем - шул да ярдәм иткәндер, бәлки. Тәүләп гаражыбыздан кибет ясадым. Уны матурлап бизәп, кәштәләр ясап, халыкка кирәк-яракларны алып, он, бодай, шикәр, сәйләр алып кайтып сатырга керештем. Халык өчен кибетләр бик аз ине ул вакытта. Шунда нигә мин яшәгән урында базар булдырмаска дигән уй керде. Базар ачарга дин урын эзләргә тотындым. 1997 елны свалка урынын юлап алып, чистартып, бар шартына китереп, кечкенә булсада базар ачып җибәрдем. Тәүдә авыр булсада, Аллага шөкер, бик куандым, - ди ул.

Уның язмышына да авыр сынаулар төшә. Чакмагыш районына барышлый юлда зур авария ясый. Руль артында - үзе, артта улы була. Мөнирәне аңын югалткан килеш дәваханәгә алып киләләр. Өч көннән соң гына аңына килә. Күзен ачу белән белгән догаларын укырга керешә һәм: "Әгәр дә исән-сау аягыма бассам, мәчет салдырам", - дип вәгдә бирә. Нижегородка мөселманнарына йөрергә ул вакытта мәчетләре булмый.

Арка үзәге чатнавы, баш миесенең селкенүенә дә бирешми, түзә. Уны дәвалаучы табибләргә рәхмәтләр укып, тизерәк өенә кайтаруларын үтенеп сорый. Ләкин табибләр уга кузгалырга да рөхсәт итми, тыныч ятарга гына киңәш итә. Мөнирә тыныч ята алмый, ул балалары янына кайтырга ашкына. Аны Тиз ярдәм машинасында носилкалар белән алып кайталар. Постельдә ятып ялкан тынгысыз җан көнне-төнен Аллаһы Тәгаләдән ярдәм сорый, догалар ятлый, сүрәләр укый. Яткан килеш намазын калдырмый. Ни могҗизә? Ул балалары хакына аягына баса, атлый башлый!

Зур хыялын тормышка ашырырга талпына ул. Иң тәүдә рөхсәт сорап кала хакимиәте башлыгы исеменә хат яза.

- Изге юлларыма тәүге фатыйхаларын бирүче Мәрйәм Солтанова исемендәге мәдрәсә директоры Илдар хәзрәт Малахов, "Галия" мәдрәсәсе директоры Ильяс хәзрәт Мухамадиев ярдәм кулы сузып, үзләренең догалары белән юлымны яктыртты. Уларга рәхмәтләрем чиксез, - ди Мөнирә ханым.

Ары ул рөхсәтләр юллап, элекке пима бастыру фабрикасын сатып ала да, ул урынны һәм күлне чистартып, нигезенә догалар укып, мәчет салдырырга керешә.

- Хәзер күлебезгә кыр үрдәкләре кайтты, менә икенче ел инде ике торна төште, - дип куана ул. - Мәчетебезнең нигезен базарымдагы эшкуарлар белән салдык. Рәхмәт аларга. Мәчетнең проектын Благовар районының егете Вәкил Дәүләтшин эшләде. Догаларым кабул булды, Аллаһы Тәгаләдән мәчетемдә намаз укырга язсын дип теләдем. Тәүдә өемдә 22ләп кеше җыелып намазлар укыдык. Хәзер иһә 45 квадрат метр майданлы зур якты мәчетебездә уку бүлмәсе урнашкан. Күл буенда алма, шомырт, балан агачлары үсә. - Мөнирә ханым киләсәктә унда теплицалар ясап, йәшелчә, җиләк-җимеш үстерергә хыяллана.

Мәчеттә Дулкын хәзрәт ял көннәрендә 20нән ашу кешегә дини белем бирә. Мөгаллимә Фатыйма ханым Фаткуллина яшьләргә һәм өлкәннәргә ислам дине нигезләрен өйрәтә. Хәмит хәзрәт Назамутдинов җомга намазларын үткәрә.

Менә нинди көчле рухлы, акыллы, сабыр, тыйнак мөселман кызы ул Мөнирә Байгилдина. Биргән вәгдәсенә тогры калып, Нижегородка мөселманнары өчен мәчет төзеткән ханымның тырышлыгы олы хөрмәткә лаек.

Материалларны Дилә БУЛГАКОВА әзерләде.